РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2015 № 12-п

*Район предприятиеләре, учреждениеләре*
*һәм бюджет оешмалары арасында Бөек Җиңүнең*
*70 еллыгы һәм Әдәбият елы уңаеннан*
*“Театр фестивале” оештыру турында*

Районыбыз хезмәт ияләренең, аеруча яшьләрнең, ялын файдалы итеп оештыру һәм хезмәт кешесенең рухи ихтыяҗын баету, халык талантларын үстерү, яшьләргә өлкәннәр тормышындагы уңай традицияләрне тапшыру максатыннан һәм шулай ук төрле яшьтәге кешеләрне мәдәният тормышына якынайту, аларның активлыгын үстерү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Район предприятиеләре, учреждениеләре һәм бюджет оешмалары арасында Бөек Җиңүнең 70 еллыгы һәм Әдәбият елы уңаеннан “Театр фестивале” үткәрергә.

2. “Театр фестивале”н үткәрү графигын, район оештыру комиссиясе составын, нигезләмәсен, жюри составын расларга (теркәлә).

3. Графикта күрсәтелгән предприятие, учреждение һәм бюджет оешмалары җитәкчеләренә коллективларында эшләүче талантлы хезмәткәрләрне җыеп, аларның “Театр фестивале”ндә катнашуын оештыруны тәэмин итәргә.

4. “Театр фестивале”нә репертуар сайлау буенча ярдәм күрсәтүне мәдәният йорты хезмәткәрләренә, район үзәк китапханәсенә тәкъдим итәргә.

5. “Саба таңнары” газетасы редакциясенә (Р.Г.Исмәгыйлов), “Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясенә (Ә.Г.Мобәрәкова) “Театр фестивале” барышын даими яктыртып баруны тәкъдим итәргә.

6. Районда булачак “Театр фестивале”ндә катнашучы коллективларга ярдәм итү өчен белгечлекләре туры килгән мәдәният хезмәткәрләрен билгеләргә.

7. “Театр фестивале”н үткәрү урыны итеп район мәдәният йортын һәм Шәмәрдән мәдәният йортын билгеләргә. Бу мәдәният йортларының җитәкчеләренә (Р.Хаҗиева, А.Габделхаков) спектакльләрне кую өчен бөтен шартларны булдыруны тәкъдим итәргә.

8. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ш.Ә.Сөнгатовка катнашкан коллективларны бүләкләү өчен финанс чыганакларын табуны тәкъдим итәргә.

9. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенец социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Т.Г.Шәрәфиевка йөкләргә.

Р.Н.Минниханов

1 кушымта

Саба муниципаль районы башлыгының

"04" февраль 2015ел

12-п карары белән расланды

Саба шәһәр җирлегендә Бөек Җиңүнең 70 еллыгына һәм Әдәбият елына багышланган "Театр фестивале"н үткәрү һәм оештыру буенча комиссия
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гасыймов Р.М. | – Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комиссиясе рәисе |
| Шәрәфиев Т.Г. | – Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары, оештыру комиссиясе рәисе урынбасары |
| Хафизов М.Г. | – Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы |
| Хәсәнов Р.М. | – Саба шәһәр җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гәрәев А.Н. | – Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Исмәгыйлов Р.Г. | – "Саба таңнары" газетасы редакторы (килешү буенча) |
| Мөбәрәкова Ә.Г. | – "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясе директоры (килешү буенча) |
| Шакиров И.Ф. | – Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы |
| Габделхаков А.Г. | – "Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы" (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Хаҗиева Р.И. | – Шәмәрдән авыл мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |

2 кушымта

Саба муниципаль районы башлыгының

“4” февраль 2015ел

12-п карары белән расланды

Бөек Җиңүнең 70 еллыгына һәм Әдәбият елына багышланган
“Театр фестивале”н үткәрү графигы

| Саба шәһәр җирлегендә | | |
|---|---|---|
| № п/п | Предприятие, учреждениеләр исемлеге | Спектакль булачак көн |
| 1 | Саба муниципаль районы «Сәләтле балалар өчен аерым предметларны тирәнтен өйрәнелә торган урта гомуми белем мәктәп-интернаты» | 27.02.2015 |
| 2 | Саба гимназиясе | 06.03.2015 |
| 3 | Саба аграр көллияте | 13.03.2015 |
| 4 | “Сабагаз” эксплуатация җитештерү идарәсе | 20.03.2015 |
| 5 | “Ак Барс” ачык акционерлык җәмгыятенең Казан филиалы Саба өстәмә офисы<br>Россия саклык банкы ачык акционерлык җәмгыятенең 4642 нче номерлы Саба бүлекчәсе<br>“Татфондбанк” АИКБ” ачык акционерлык җәмгыятенең Байлар Сабасы өстәмә офисы<br>“Россельхозбанк” ачык акционерлык җәмгыятенең Татарстан региональ филиалы Байлар Сабасы ш.т.б. өстәмә офисы | 27.03.2015 |
| 6 | “Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыяте | 03.04.2015 |
| 7 | Район үзәк шифаханәсе<br>31 нче номерлы район үзәк аптекасы<br>“Казан аптекалары” | 10.04.2015 |
| 8 | Россия эчке эшләр министрлыгының “Саба” муниципальара бүлеге<br>“Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясе<br>“Саба таңнары” газетасы редакциясе | 17.04.2015 |
| 9 | Район почта элемтәсе идарәсе<br>Район электр элемтәсе узелы<br>Район электр челтәре, Энергосбыт, Энергонадзор | 24.04.2015. |
| 10 | Район халыкны социаль яклау бүлеге<br>“Балкыш” социаль хезмәт күрсәтү үзәге<br>Шәмәрдән реабилитация үзәге<br>Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | 01.05.2015 |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | “Олимп” балалар–яшүсмерләр спорт мәктәбе<br>“Спорткомплекс” муниципаль учреждениесе<br>“Саба йозү бассейны физкультура-сәламәтләндерү комплексы” муниципаль учреждениесе | 15.05.2015 |
| 12 | Сак бүлеге (отдел охраны)<br>Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе<br>ТР хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге<br>Татарстан Республикасындагы Федераль миграция идарәсенең Саба районындагы бүлекчәсе<br>Прокуратура, Район суды, Суд приставлары хезмәте, Адвокатура | 22.05.2015 |
| 13 | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы 10 нчы номерлы районара инспекциясе | 02.10.2015 |
| 14 | “Саба МТС” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Сабагрохим” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Илфани”, “Тулпар”, “Сабинскагропромснаб” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Сабагро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 09.10.2015 |
| 15 | ТР буенча Федераль казначылык идарәсенең Саба районы буенча бүлеге<br>Саба муниципаль районы Финанс–бюджет палатасы<br>ТР финанс министрлыгы казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлекчәсе | 16.10.2015 |
| 16 | Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемология үзәгенең Саба районы филиалы | 23.10.2015 |
| 17 | “Рамазан” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Яшен” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 30.10.2015. |
| 18 | РФ пенсия фонды идарәсенең ТР Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе<br>Район кулланучылар җәмгыяте берлеге идарәсе<br>“ПМК-159” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 06.11.2015 |
| 19 | “Татавтодор” ААҖ Саба филиалы | 13.11.2015 |
| 20 | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Саба муниципаль район Советы<br>Саба муниципаль районы мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы<br>Саба муниципаль районы авыл хуҗалыгы идарәсе | 20.11.2015. |
| 21 | “Экопродукт” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Саба тәрәзәләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Автотранспорт” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Бердәм тәрәзә” хезмәте | 27.11.2015 |
| 22 | Саба муниципаль районы гражданнар саклау идарәсе<br>Татарстан Республикасы ирекле янгынга каршы | 04.12.2015 |

| | | |
|---|---|---|
| | көрәш җәмгыятенең Саба районы филиалы<br>Татарстан Республикасы буенча 129 нчы янгын сүндерү часте<br>Татарстан Республикасы зона эзләү–коткару хезмәтенең 4 отряды (Шәмәрдән) | |
| 23 | Саба районы дәүләт ветеринария берләшмәсе<br>“Универмаг” сәүдә үзәге<br>“Герат” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“Мир” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>“ФРГ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br>ЧП “Хасанов”, ЧП “Мубаракзянов”<br>ЧП “Иванов”, ИП Хасанов Б.Х. | 11.12.2015 |
| 24 | “Россгострах” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасындагы филиалы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе Агентлыгы<br>Көнкүреш йорты<br>Саба үзәк китапханәсе<br>Балалар сәнгать мәктәбе<br>Балалар иҗат үзәге | 18.12.2015 |
| | Шәмәрдән зонасы буенча | |
| 1 | Шәмәрдән лицее | 07.02.2015 |
| 2 | Шәмәрдән участок шифаханәсе | 14.02.2015 |
| 3 | Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр линия-җитештерү идарәсе | 21.02.2015 |
| 4 | “Торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе” ААҖ | 28.02.2015 |
| 5 | “ТАТМИТАгро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 07.03.2015 |
| 6 | “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе” ААҖ | 14.03.2015 |
| 7 | Югары Утар балалар интернаты | 21.03.2015 |
| 8 | “Татнефтепродукт” ААҖ “Шәмәрдәннефтепродукт” филиалы | 28.03.2015 |
| 9 | “Яшьлек” яшьләр мәдәни-спорт үзәге, Шәмәрдән сәнгать мәктәбе | 04.04.2015 |
| 10 | “ТАТАгро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 11.04.2015 |
| 11 | Шәмәрдән тимер юл станциясе | 18.04.2015 |

3 кушымта

Саба муниципаль районы башлыгының

“4” февраль 2015ел

12-п карары белән расланды

Районда үзәгендә Бөек Җиңүнең 70 еллыгына һәм Әдәбият елына багышлаган “Театр фестивале”н үткәрү

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

1. “Театр фестивале” 2015 елның февраль, март, апрель, май, октябрь, ноябрь, декабрь айларында район һәм Шәмәрдән мәдәният йортларында үтә.

2. Спектакльне бәяләү өчен жюри составы мәдәният белгечләре катнашында төзелә. “Театр фестивале” бәйге рәвешендә үткәрелә.

3. Чыгыш ясау вакыты һәр коллектив өчен бер сәгать ярым яисә ике сәгать бирелә. Спектакльләр 5 (биш) баллы система белән бәяләнә.

4. Уңышлы дип саналган спектакльләр 2016 нчы елда фестивальнең район үзәгендә һәм Шәмәрдәндә булачак йомгаклау кичәләренә чакырыла.

4 кушымта

Саба муниципаль районы башлыгының

“__4__” __февраль__2015ел

__12-п__карары белән расланды

Район үзәгендә Бөек Җиңүнең 70 еллыгына һәм Әдәбият елына багышлап “Театр фестивале”н үткәрү буенча жюри составы

Саба зонасы буенча

| | |
|---|---|
| Зиннуров А.М. | – “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йөрты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Габделхаков А.Г. | – “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов М.Р. | – район мәдәният йорты өлкән методисты (килешү буенча) |
| Габделхакова М.Т. | – район мәдәният йорты “Ләйсән” сәнгать бригадасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Габделхаков Г.Г. | – район мәдәният йортының үзешчән сәнгать җитәкчесе (килешү буенча) |
| Тимербаева З.З. | – район мәдәният йорты үзешчән сәнгать буенча методисты (килешү буенча) |
| Тимербаев Х.Р. | – “Саба чишмәләре” клуб берләшмәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Зарипова Ф.М. | – район мәдәният йортының клуб эшләре методикасы буенча белгеч (килешү буенча) |
| Нурмөхәммәтова Г.В. | – “Саба үзәкләштерлегән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 57 нче номерлы филиал мөдире (күчмә клуб) (килешү буенча) |
| Нурисламова Э.И. | – “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 56 нче номерлы филиал мөдире (күчмә клуб) (килешү буенча) |
| Мансурова Л.Ф. | – “Саба үзәкләштерлегән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 58 нче номерлы филиал мөдире (күчмә клуб) (килешү буенча) |

Шәмәрдән зонасы буенча

| | |
|---|---|
| Хаҗиева Р.И. | – Шәмәрдән авыл мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| Әсретдинова Р.С. | – Шәмәрдән авыл мәдәният йортының үзешчән сәнгать җитәкчесе (килешү буенча) |
| Зәйнетдинова Р.С. | – Шәмәрдән авыл мәдәният йорты методисты (килешү буенча) |
| Аксанова Л.М. | – Балалар сәнгать мәктәбенең Шәмәрдән филиалы мөдире (килешү буенча) |
| Вәлиева А.М. | – Шәмәрдән авыл мәдәният йортының мәдәни чаралар оештыручысы (килешү буенча) |